Раслыйм
«Сәләт» ТРЯИФ
Генераль директоры
__________ Җ.Ш. Сөләйманов
«_9_» _ноябрь_________ 2020

Сәләтле балаларны һәм яшьләрне үстерү өлкәсендә VI «Сәмрух»
республика ел премиясе

НИГЕЗЛӘМӘ

1. Премиянең оештыручылары.

Татарстан Республикасы «Сәләт» яшьләр иҗтимагый фонды тарафыннан Татарстан Республикасы хөкүмәте ярдәме белән оештырыла.

2. Премиянең максаты һәм бурычлары.

Премиянең максаты: Сәләт хәрәкәтендә катнашучы сәләтле балаларны һәм талантлы яшьләрне бүләкләү, Сәләт активистларының, партнерларының, Сәләт проектлары авторларының һәм оештыручыларның эшенә бәя бирү.

Премиянең бурычлары:

- ел дәвамында Сәләт проектларында катнашып, Рәсәйдә һәм чит илләрдә Татарстан исемен уңай яңгыратуга үз өлешләрен керткән сәләтле балаларны һәм мөгаллимнәрне бүләкләү;
- бүгенге җәмгыятьтә интеллект һәм рухны беренче урынга кую идеяләрен алга этәрү;
- прогрессив фикерләүгә, этник индивидуальлек һәм гомумкешелек сыйфатларына ия булган иҗади-интеллектуаль элита үстерүдә катнашу;
- Сәләт хәрәкәтендә катнашучы балаларда иҗади һәм иҗтимагый активлык дәрәҗәсен арттыру;
- Татарстан Республикасы яшь лидерларында позитив иҗтимагый һәм профессиональ имидж булдыру.

3. Премиядә катнашучылар.

Ел саен уздырылучы «Сәмрух» исемле Республикакүләм сәләтле балалар һәм талантлы яшьләр премиясендә Сәләт хәрәкәтендә актив балалар, яшьләр, укытучылар катнаша.

Бер номинациядә җиңү яулаган катнашучы икенче елда шул ук номинациядә катнаша алмый.

Ярышта катнашучылар гаризаны бары тик 1 яки 2 номинациядә генә тапшыра алалар.

## 4. Премияне уздыру шартлары, тәртибе һәм вакыты.

Премия өч этапта уздырыла:

1-нче этап – «Гаризалар кабул итү».

Катнашучылар гаризаны расланган форма белән www.selet.biz сайтында тутыралар һәм портфолиоларын Оештыру комитетына җибәрәләр.

Вакыты – **2020 елның 30-нчы ноябренә** кадәр.

2-нче этап – «Катнашучыларны сайлап алу. Читтән торып катнашу этабы».

Катнашучыларны портфолио нигезендә сайлап алу.

Вакыты – **2020 ел, 1-нче декабрь - 4-нче декабрь**.

3-нче этап – «Катнашучыларны әңгәмә нигезендә сайлап алу».

Кандидатлар белән әңгәмәне экспертлар советы уздыра һәм бәя бирә, аның төп максаты – катнашучының эшчәнлеге турында тулырак мәгълүмат алу.

Биремнәрнең формасын һәм эчтәлеген экспертлар билгели. Конкурс уздырылуга 5 көн кала, уздырылу урыны, вакыты һәм конкурсның эчтәлеге хакында хәбәр ителә.

Вакыты – **2020 елның 8-нче декабреннән - 2021 елның 19-нчы гыйнваренә кадәр**.

4 этап – «Тантаналы рәвештә премияне тапшыру».

**2021 ел, февраль** – лауреатларны һәм премиянең җиңүчеләрен бүләкләү.

Тантананы үткәрү датасы һәм вакыты Оештыру комитеты тарафыннан өстәмә рәвештә хәбәр ителә. Көтелмәгән шартлар килеп чыккан очракта, Оештыру комитеты премиянең уздыру этапларын үзгәртергә мөмкин.

## 5. Премия номинацияләре һәм бәя бирү шартлары.

Ел саен уздырылучы «Сәмрух» исемле Республикакүләм сәләтле балалар һәм талантлы яшьләр премиясе түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

**«Ел директоры» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шарт:

- әлеге номинациядә бары тик «Сәләт 2020» профильле аланнар директорлары гына катнаша ала.

Бәя бирү критерийлары:

- Сәләт берләшмәсе эшчәнлегендә актив катнашу;
- Сәләт берләшмәсендә казанышларга ия булу;
- Сәләт профильле аланында әйдаманлык тәҗрибәсе булу;

- номинант җитәкләгән аланның уңышлары булу;
- шәхси һәм профессиональ уңышларга ия булу;
- Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә сөйләшә белү;
- педагогик ситуацияләр вакытында дөрес чишелеш таба белү;
- «Сәләт» Татарстан Республикасының яшьләр иҗтимагый фонды, «Сәләт» яшьләр үзәге Дәүләт учреждениесе, смена базалары җитәкчеләре бәяләмәсе.

**«Ел өлкән әйдаманы» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шарт:

- әлеге номинациядә бары тик «Сәләт 2020» профильле аланнарның өлкән әйдаманнары гына катнаша ала.

Бәя бирү критерийлары:

- Сәләт берләшмәсе эшчәнлегендә актив катнашу;
- Сәләт берләшмәсендә казанышларга ия булу;
- Сәләт профильле аланында әйдаманлык тәҗрибәсе булу;
- номинант җитәкләгән «Сәләт 2020» профильле аланының уңышлары булу;
- шәхси һәм профессиональ уңышларга ия булу;
- Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә сөйләшә белү;
- педагогик ситуацияләр вакытында дөрес чишелеш таба белү;
- «Сәләт» Татарстан Республикасының яшьләр иҗтимагый фонды, «Сәләт» яшьләр үзәге Дәүләт учреждениесе, смена базалары җитәкчеләре бәяләмәсе.

**«Ел аланы» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шарт:

- әлеге номинациядә бары тик «Сәләт 2020» профильле аланнары гына катнаша ала.

Бәя бирү критерийлары:

- аланда катнашучыларның шәһәр, республика, ил күләмендә казанышлары;
- «Сәләт 2020» җәйге профильле алан уздыру өчен смена командасы төзегән махсус методик күрсәтмәләр булу;
- «Сәләт 2020» җәйге аланының эшчәнлеге сайланган профильгә туры килүе (уку-укыту, массакүләм һәм спорт чаралары, укудан тыш программа, идеология);
- алан эшчәнлегенең социаль челтәрләрдәге үз пабликларында, район, республика, ил ММЧларында яктыртылуы;
- аланның профиль һәм тематик эшчәнлеген ел дәвамында алып бару;
- аланда татар телле мохит булдыру өчен кулланылган ысуллар һәм чаралар;
- аланның 2019 - 2020-нче елларда ирешкән уңышлары.

**«Ел сәлкеше» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шартлар:

- әлеге номинациядә 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәр булган, Сәләт хәрәкәтендә активлыгы 2 елдан да ким булмаган сәлкешләр катнаша ала.

Бәя бирү критерийлары:

- Сәләт хәрәкәтенең эшчәнлегендә актив катнашу;
- Сәләт хәрәкәтендә казанышларга ия булу;
- укуда югары өлгереш (гаризага уку урыныннан алынган, соңгы уку елындагы өлгереш турында белешмә беркетелә);
- Сәләт профильле аланының уңышларында өлеше булу;
- массакүләм мәдәни һәм спорт чараларында катнашу;
- җәмгыять эшендә катнашу;
- Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә сөйләшә белү.

**«Ел әйдаманы» номинациясе.**

Әлеге номинациянең лауреатлары һәм җиңүчесе Республикакүләм «Әйдаманнар ярышы 2020» бәйгесе нәтиҗәләре нигезендә билгеләнә.

**«Ел клубы» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шартлар:

- Сәләт хәрәкәтендә кимендә бер ел эшчәнлек тәҗрибәсе булган клублар гына катнаша.

Бәя бирү критерийлары:

- клуб әгъзаларының укуда өлгерүе;
- клуб әгъзаларының олипиадаларда, конкурсларда каташуы;
- клуб әгъзаларының мәктәп, район, шәһәр, республика, ил күләмендә казанышлары;
- клубның проектлар белән эшләү тәҗрибәсе;
- клубның эшчәнлеген социаль челтәрдәге үзенең паблигында яктырту, район, шәһәр, республика, ил ММЧларында күрсәтү;
- активистлар санының еллык үсеш тенденциясе;
- клуб әгъзаларының «Сәләт 2020» җәйге аланнырында катнашуы;
- клуб активлыгы белән «Сәләт 2020» җәйге аланнарында катнашкан балалар саны;
- клуб әгъзаларының Сәләтнең 2020-нче елда узган башка чараларында катнашуы;
- клубта татар телле мохит булу;
- клубның 2019 - 2020-нче елларда ирешкән уңышлары;
- партнёрство с другими региональными клубами «Сэлэт».

**«Ел кулдашлары» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шарт:

- әлеге номинациядә Сәләтнең 2020-нче елның профильле сменасында кулдаш буларак (бер төркемдә) эшләгәннәр генә катнаша ала.

Бәя бирү критерийлары (һәр кулдашка бәя бирелә) :

- Сәләт берләшмәсендә актив катнашу;
- Сәләт берләшмәсендә алган казанышлары;
- Сәләт берләшмәсенең сменаларында әйдаман буларак актив эшчәнлек алып бару;
- җәйге аланда катнашкан балаларның сменадан соң казанышлары булу;
- шәхси һәм профессиональ казанышлары;
- Татарстан Республикасы дәүләт телләрен югары дәрәҗәдә белү;
- «Сәләт» Татарстан Республикасының яшьләр иҗтимагый фонды, «Сәләт» яшьләр үзәге Дәүләт учреждениесе, җәйге смена базалары җитәкчеләре, сменаның өлкән әйдаманы, сменаның директоры бәяләмәсе;
- педагогик ситуацияләр вакытында дөрес чишелеш таба белү;
- балалар һәм әни-әтиләр бәяләмәсе.

**«Ел инициативасы» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шарт:

- әлеге номинациядә төбәк «Сәләт» клублары һәм Сәләт активы мәктәбе проект төркемнәре эшчәнлеге кысаларында тормышка ашырылып, уңышка ирешкән проектлар катнаша. Проектны тормышка ашыру вакыты бер айдан да ким түгел.

Бәя бирү критерийлары:

- җәмгыять өчен социаль әһәмияткә ия булу;
- Сәләт берләшмәсе кысаларында проектның актуальлеге һәм яңалыгы;
- проектларны уңышлы тормышка ашыруда команда тәҗрибәсе һәм муниципалитет, республика һәм ил күләмнәрендә команда әгъзалары казанышлары;
- проектның колачы (катнашучылар саны һәм географиясе);
- проектның уңышы – сан һәм сыйфат индикаторларына карап, ирешелгән уңышлар;
- киләчәктә проектны чынга ашыру перспективалары.

**«Сәләт җырлый» номинациясе.**

Номинациядә катнашу өчен мөһим шарт:

- әлеге номинациядә 2019 - 2020-нче елларда авторлык җыры (сүзләре һәм көе авторлар тарафыннан иҗат ителгән, шулай ук автор аранжировкалары да булырга мөмкин) катнаша ала.

Бәя бирү критерийлары:

- шигырь текстының сәнгати дәрәҗәсе;
- музыканың оригинальлеге;
- әсәрнең композиция бөтенлеге.

## 6. Премиянең Оештыру комитеты.

Оештыру комитеты Премияне әзерләү һәм уздыру өчен «Сәләт» клубы әгъзаларыннан, «Сәләт», фонды һәм «Сәләт» яшьләр үзәге хезмәткәрләреннән туплана. Оештыру комитетының составы ТРЯИФ генераль директоры тарафыннан раслана.

Оештыру комитеты:

- премияне оештыруны һәм уздыруны әзерли;
- премия уздыруның һәр этабын администрацияли;
- премия программасының һәр этабын уздыруны билгели һәм раслый;
- үткәрү вакытын һәм урынын билгели;
- махсус номинацияләр билгели ала.

## 7. Премиянең экспертлар советы.

«Катнашучыларны сайлап алу» этабын оештыру һәм билгеләү өчен Экспертлар советы булдырыла. Аның составы «Сәләт» ТРЯИФ генераль директоры тарафыннан раслана.

Экспертлар советы составына Дәүләт органнары хезмәткәрләре, танылган җәмәгать эшлеклеләре, фән, мәгариф, мәдәният хезмәткәрләре керә.

Экспертлар советы беренче этапта кабул ителгән конкурс материалларын бәяли. Катнашучыларны әңгәмә нигезендә сайлап алу этабында конкурсантка бәя бирә һәм премиянең җиңүчесен билгели.

Экспертлар советы өстәмә рәвештә махсус бүләкләр һәм номинацияләр билгели ала.

## 8. Гариза тутыруга таләпләр.

Катнашучы заявкасында тутырылган гариза һәм электрон портфолио булырга тиеш. Портфолио нидән гыйбәрәт:

- резюме, тәкъдим итү хатлары, бәяләмәләр;
- дипломнар, рәхмәт хатлары, грамоталар, мактау грамоталары, сертификатлар;
- иллюстрацияләр (фотосүрәтләр, басма массакүләм мәгълүмат чараларыннан копияләр, видеоматериаллар һ.б.);
- соңгы ике ел эчендә ирешкән уңышларны раслаучы башка документлар.

Формаль шартлар:

- документ тутыру: текстлар уку өчен аңлаешлы, укырга җайлы итеп һәм битнең бер ягына язылырга тиеш;

- катнашучының уңышларын раслаучы документлар (дипломнар, бүләкләнүләр, рәхмәт хатлары, басма матбугат чараларында чыккан язмалар) электрон рәвештә (копия яки сыйфатлы фото) һәм бер документка туплап тапшырылырга тиеш;
- иллюстрацион материаллар, гаризалар (фото һәм видео) электрон форматта документлар белән бер файлда бирелергә тиеш.

9. Гаризаны тапшыру тәртибе.

Гариза тапшыру вакыты – **2020 елның 30-нчы ноябреннән** дә соңрак булырга тиеш түгел.

Электрон портфолиолар флешкада оештыру комитетына тапшырыла. Оештыру комитеты адресы: Сәләт йорты, Казан шәһәре, Островский урамы, 23-нче йорт, 3-нче бүлмә. Яки оештыру комитетының электрон почтасына samruh@selet.biz җибәрелә.

Белешмә өчен телефон: + 7 (843) 292 - 16 - 00.

Әлеге нигезләмәгә туры килмәгән гаризалар конкурста каралмый.

Премия нәтиҗәләре билгеле булгач, конкурс материаллары кайтарылырга мөмкин.

Гаризалар саны аз булган очракта, Оештыру комитеты гаризалар кабул итү этабын озайта ала, яки кайсыдыр номинациядә ярыш уздырылмаска мөмкин.